ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 16** **12 май 2025 ел**

*«Су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм кешеләрнең һәлак булуын булдырмау чаралары турында»*

2025 елның җәйге чорында суда кешеләр һәлак булуны булдырмау максатларында 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Россия Федерациясе кануны нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Җирлек торак пунктларының су объектларында кешеләрнең һәлак булуын тәэмин итүне профилактикалау һәм булдырмау чаралары планын җәйге чорга расларга (1 нче кушымта)
2. Су объектлары янындагы массакүләм ял итү урыннарында күрсәтмә стендлар урнаштырырга.
3. Су объектлары янында ял иткәндә, су коенганда, балык тотканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча халык белән аңлату - профилактика эшләрен киң башкарырга.
4. Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе директорына «Тормыш иминлеге нигезләре» курсының уку программасы кысаларында, сыйныф чаралары үткәргәндә, шулай ук балалар белән җәйге савыктыру чорында белем бирү учреждениеләрендә укучыларны суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өстәмә өйрәтүне күздә тотарга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Э.Ф.Исхакова

Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма
комитетының 2025 елның 12 маендагы
16 санлы карарына
1 кушымта

**Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге торак пунктларының су объектларында кешеләрнең һәлак булуын тәэмин итүне профилактикалау һәм булдырмау чаралары планы**

| № п.п. | Чара исеме | Башкару вакыты | Җаваплылар | Искәргә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җирлек торак пунктларының су объектларында кешеләрнең һәлак булуын булдырмауны профилактикалау чараларын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга | июнь | Җирлек Советы депутатлары | |
| 2. | Җәйге каникулларга кадәр мәктәпләрдә су объектларында кешеләрнең һәлак булуын тәэмин итүне һәм булдырмауны профилактикалау буенча балалар белән әңгәмәләр һәм эш алып барырга | Июнь | Кәрәкәшле мәктәбе директоры, балалар бакчасы мөдире | |
| 3. | Халык арасында тиешле аңлату эшләре башкарырга, белешмәләр таратырга, суда массакүләм ял итү урыннарында күрсәтмә стендлар урнаштырырга | Июнь | Җирлек Советы депутатлары | |